МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.09.2017 ел № 02-90

Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.03.2016 ел, № 02-32, 29.06.2016 ел, № 02-73, 30.09.2016 ел, № 02-116, 27.12.2016 ел, № 02-157, 29.12.2016 ел, № 02-159, 31.03.2017 ел, № 02-30, 30.06.2017 ел, № 02-64 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
26 сентябрь, 2017 ел,

№ 02-90 боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр**

1. “Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре” 2 пунктында:

а) “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм” дәүләт программасы” 2.3. пунктчасында «03 5 03 00000 “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру” төп чарасы” максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

“- 13140 Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер тапкыр түләнелә торган өстәмә акчалата түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер тапкыр түләнелә торган өстәмә акчалата түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.”;

б) “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады” дәүләт программасы” 2.11. пунктчасында «11 8 00 00000 “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать мәйданчыкларын оештыру һәм үстерү” кече программасы” максатчан статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге максатчан статья буенча түбәндәге төп чаралар буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

11 8 01 00000 “Хосусый индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын оештыру” төп чарасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 60770 “Алабуга” сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона” акционерлык җәмгыятенә “Алабуга-2” сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона” индустриаль паркы (“Алабуга-2” индустриаль паркы) идарәче компаниясенә инфраструктура объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә субсидияләр

- 60780 “Алабуга-2. Нефть химиясе” идарәче компаниясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә инфраструктура объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә субсидияләр

11 8 02 00000 “Россия кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү” төп чарасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 60870 Россия кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр”;

в) “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы” 2.14. пунктчасында “14 7 03 00000 “Мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү” төп чарасы” максатчан статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 60180 Авыл җирлегендә мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча авыл җирлегендә мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү чараларын тормышка ашыру максатында субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең “Дәүләт (муниципаль) милек объектларына капитал салуларны финанслашуга бюджетларга субсидияләр” 000 2 02 20077 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- R0180 “2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы чараларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча “14 7 03 00000” төп чарасы кысаларында, мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү ягыннан, “Авыл җирлекләрен тотрыклы үстерү” кече программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең “Дәүләт (муниципаль) милек объектларына капитал салуларны финанслашуга бюджетларга субсидияләр” 000 2 02 20077 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.”;

г) “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү” дәүләт программасы 2.23. пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге максатчан статья өстәргә:

“24 К 00 00000 “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү” дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү” кече программасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт”.

2. 2 нче кушымтада:

а) юлны

| | |
|---|---|
| “03 2 01 R2090 | Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә, эшләмәүче пенсионерларны компьютерда эшләргә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар” |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| “03 2 01 R2090 | Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә, эшләмәүче пенсионерларны компьютерда эшләргә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар”; |

б) юлны

| | |
|---|---|
| “03 3 02 R2090 | Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә, эшләмәүче пенсионерларны компьютерда эшләргә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар” |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| “03 3 02 R2090 | Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә, эшләмәүче пенсионерларны компьютерда эшләргә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар”; |

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| “03 5 03 13130 | Опекуннар гаиләләренә тәрбиягә алган балаларын карауга түләүләр” |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «03 5 03 13140 | Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер тапкыр түләнелә торган өстәмә түләү”; |

г) юлны

| | |
|---|---|
| “11 8 01 60770 | “Алабуга-2” индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә чыгымнарның бер өлешен каплауга “Алабуга-2” индустриаль паркы идарәче компаниясенә субсидияләр |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| “11 8 01 60770 | “Алабуга” сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона” акционерлык җәмгыятенә инфраструктура объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә “Алабуга-2” сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы” индустриаль паркы (“Алабуга-2” идустриаль паркы) идарәче компаниясенә субсидияләр” |

һәм шуннан соң түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| “11 8 01 60780 | “Алабуга-2”. Нефть химиясе идарәче компаниясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә инфраструктура объектларын булдыруга, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә субсидияләр |
| 11 8 02 00000 | “Россия кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле рәвештә чыгымнарны субсидияләү” төп чарасы |
| 11 8 02 60870 | Россия кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле рәвештә чыгымнарны каплауга субсидияләр”; |

д) юлдан соң

| | |
|---|---|
| “14 7 03 00000 | “Мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү” төп чарасы |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| “14 7 03 60180 | Авыл җирлегендә мәйданчыкларны җыйнак торак төзелеше өчен комплекслы төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга субсидияләр”; |

е) юлдан соң

| | |
|---|---|
| “24 2 01 23030 | Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе институтын үстерү” |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| “24 К 00 00000 | “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү” дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү” кече программасы |
| 24 К 00 72310 | Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт”. |